| ГЛАВА<br>РЫБНО-СЛОБОДСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАЛЫК БИСТӘСЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.10.2023 Балык Бистәсе штп. № 219 пг

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану (керү) мөмкинлеген тәэмин итү хакында

«Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы Федераль законның 10, 14 маддәләренә, «Татарстан Республикасы дәүләт органнары һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» 2015 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 маддәсенә, «Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» Федераль законны Татарстан Республикасында тормышка ашыру чаралары турында» 2009 елның 12 декабрендәге 281 номерлы Татарстан Республикасы Президенты күрсәтмәсенә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» 2009 елның 31 декабрендәге 919 номерлы карарын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Расларга (кушымта итеп биреләләр):

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат исемлеге;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарының һәм аларга буйсынучы оешмаларның рәсми сайтыннан файдалануны тәэмин итүнең технологик, программа һәм лингвистик чараларына таләпләр.

2. Әлеге карарның 1 пунктында каралган мәгълүмат бирү өчен җаваплы затларга түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

әлеге карарның 1 пунктында каралган мәгълүматны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының гомуми бүлек башлыгы (мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүмати куркынычсызлык буенча) урынбасарына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру өчен тапшыру срокларын үтәүне;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм аларга буйсынучы оешмалар эшчәнлеге турында рәсми сайтта урнаштырыла торган мәгълүматның дөреслеге һәм вакытында яңартылуын.

3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының гомуми бүлеге башлыгының (мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүмати куркынычсызлык буенча) урынбасарына тәкъдим итәргә:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнары һәм алар буйсынуындагы оешмалар эшчәнлеге турындагы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырыла торган мәгълүматлар исемлеге нигезендә әлеге карар белән расланган мәгълүматны, чикләнгән файдалану мөмкинлеге мәгълүматыннан тыш, урнаштыруны;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм аларга буйсынучы оешмалар эшчәнлеге турында мәгълүматны рәсми сайтта урнаштыру срокларын үтәүне;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм аларга буйсынучы оешмалар эшчәнлеге турында рәсми сайтта урнаштырыла торган мәгълүматның дөреслеге һәм вакытында яңартылуын.

4. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» 2016 елның 8 сентябрендәге 117пг номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында - һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгы урынбасары Ф.Г.Әхмәтҗановага йөкләргә.

Башлык Р.Р. Ислямов

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН СОВЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ
Р.07-3577/02
ИНН 1634005057

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Башлыгының
2023 елның 13 октябре
219 пг номерлы карары
белән расланды

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм аларга буйсынучы оешмалар эшчәнлеге турында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырыла торган мәгълүмат исемлеге**

| № п/п | Мәгълүматның категориясе | Урнаштыруның периодиклыгы (кабатлану вакыты) | Мәгълүмат бирүгә җаваплы башкаручылар | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының гомуми бүлеге башлыгы (мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүмати куркынычсызлык буенча) урынбасарына мәгълүмат бирү вакыты (срогы) |
|---|---|---|---|---|
| **I. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында гомуми мәгълүмат** | | | | |
| 1. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарының тулы һәм кыскартылган аталышы (исеме), почта адресы, кулланучылар тарафыннан гарызнамәләрне җибәрү һәм соралган мәгълүматны алу өчен | Актуаль хәлдә саклана (тотыла) | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының гомуми бүлеге башлыгы (мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүмати куркынычсызлык буенча) урынбасары (килешенү буенча) | Тиешле (тиңдәшле) үзгәрешләр кертелгәннән соң 5 эш көне эчендә |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | электрон почта адресы, белешмәләр хезмәтенең телефон номерлары, матбугат хезмәте һәм ышаныч телефоны (булган очракта) | | | |
| 2. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарының вәкаләтләре, аларның структур бүлекчәләренең бурычлары һәм функцияләре турында мәгълүматлар, шулай ук Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарының вәкаләтләрен, бурычларын һәм функцияләрен билгеләүче норматив хокукый актлар исемлеге | Тиешле норматив хокукый һәм башка актлар расланганнан яки үзгәртелгәннән соң 5 эш көне эчендә. Норматив хокукый актлар исемлеге актуаль хәлдә саклана | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы рәисе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Контроль-хисап палатасы рәисе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппаратының юридик бүлеге башлыгы | Тиешле (тиңдәшле) норматив хокукый һәм башка актлар расланган яки үзгәртелгән көннән алып 3 эш көне эчендә |
| 3. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнары структурасы | Структураны раслаганнан яки үзгәрткәннән соң 5 эш көне эчендә | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының гомуми бүлеге башлыгы (мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүмати иминлек буенча) урынбасары (килешенү буенча), Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппаратының юридик бүлеге башлыгы | Структураны раслаганнан яки үзгәрткәннән соң 3 эш көне эчендә |
| 4. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары, аларның структур бүлекчәләре (бүлекләре) җитәкчеләре турында мәгълүматлар, аерым алганда, фамилияләр, исемнәр, аталарының исемнәре, шулай ук күрсәтелгән затларның ризалыгы белән алар турында башка мәгълүматлар | Билгеләнүдән соң 3 эш көне эчендә. Актуаль хәлдә саклана | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының гомуми бүлеге башлыгы (мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүмати иминлек буенча) урынбасары (килешенү буенча) | Билгеләнүдән соң 1 эш көне эчендә |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 5. | Ведомство карамагындагы оешмаларның исемлеге (булган очракта), аларның бурычлары һәм функцияләре турында мәгълүматлар, шулай ук почта адреслары, электрон почта адреслары, ведомство карамагындагы оешмаларның белешмә хезмәтләренең телефон номерлары | Оешманы булдыру турында хокукый актка кул куелганнан соң 5 эш көне эчендә. Актуаль хәлдә саклана | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарының эшчәнлекнең тиешле юнәлешләрен (килешенү буенча) күзәтүчелек (кураторлык) итүче структур (функциональ) бүлекчәләре җитәкчеләре, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының гомуми бүлеге башлыгы (мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүмати иминлек буенча) урынбасары (килешенү буенча) | Оешманы булдыру турында хокукый актка кул куелганнан соң 3 эш көне эчендә. |
| **II. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарының норма эшләү (иҗат итү) эшчәнлеге турында мәгълүмат** | | | | |
| 6. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органы тарафыннан чыгарылган муниципаль хокукый актлар (карарлар, боерыклар, кагыйдәләр, инструкцияләр, нигезләмәләр һәм башка актлар), аларга үзгәрешләр кертү турындагы мәгълүматларны да кертеп, аларны үз көчләрен югалткан дип тану, шулай ук Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән очракларда муниципаль хокукый актларны дәүләт теркәве турында мәгълүмат | Тиешле (тиңдәшле) документ кабул ителгәннән (расланганнан) соң 5 эш көне эчендә | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы рәисе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Контроль-хисап палатасы рәисе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлеге башлыгы (килешенү буенча), Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппаратының оештыру бүлеге башлыгы урынбасары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппаратының юридик бүлеге башлыгы | Тиешле документ кабул ителгәннән (расланганнан) соң 3 эш көне эчендә |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 7. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актларын гамәлдә түгел дип тану турындагы эшләр буенча суд карарлары турында мәгълүматлар | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органына суд карары кергәннән соң 5 эш көне эчендә | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппаратының юридик бүлеге башлыгы | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органына суд карары кергәннән соң 3 эш көне эчендә |
| 8. | Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең административ регламентлары һәм стандартлары | Алар расланганнан соң 5 эш көне эчендә | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге башлыгы (килешенү буенча) | Алар расланганнан соң 3 эш көне эчендә |
| 9. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарының һәм аларның вазыйфаи затларының муниципаль хокукый актларына һәм гамәлләренең (гамәл кылмауларының) башка карарларына карата суд һәм административ тәртиптәге шикаятьләр | Актуаль хәлдә саклана | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге башлыгы (килешенү буенча), Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппаратының юридик бүлеге башлыгы | Актуаль хәлдә саклана |
| **III. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарының агымдагы эшчәнлеге турында мәгълүмат (компетенция чикләрендә)** | | | | |
| 10. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелә торган (башкарыла торган) дәүләт, муниципаль хезмәтләр һәм аларны бирү (башкару) тәртибе турында мәгълүматлар | Актуаль хәлдә саклана | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге башлыгы (килешенү буенча) | Дәүләт, муниципаль хезмәтләр исемлеге расланганнан соң яки аңа үзгәрешләр кертелгәннән соң 3 эш көне эчендә |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 11. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары эшчәнлеге планнары һәм күрсәткечләре | План яки күрсәткеч расланганнан соң 5 эш көне эчендә | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге башлыгы (килешенү буенча) | План яки күрсәткеч расланганнан соң 3 эш көне эчендә |
| 12. | Федераль максатчан һәм (яки) дәүләт, муниципаль программаларны тормышка ашыру нәтиҗәләре, максатчан күрсәткечләрне үтәү турында, максатчан һәм (яки) дәүләт, муниципаль программаны үтәүгә тотылган финанс ресурслары күләме, шулай ук программа чараларын тормышка ашыруны мониторинглау нәтиҗәләре турында төп мәгълүматлар | Квартал саен | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге башлыгы (килешенү буенча) | Квартал саен |
| 13. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматлар һәм аналитик материаллар (докладлар, хисаплар һәм мәгълүмат сыйфатындагы күзәтүләр) | Актуаль хәлдә саклана | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге башлыгы (килешенү буенча) | Материаллар әзерләнгәннән соң 3 эш көне эчендә |
| 14. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарәнең башка органнары, иҗтимагый берләшмәләр, сәяси фиркаләр, һөнәри берлекләр һәм башка оешмалар, шул исәптән халыкара оешмалар белән үзара хезмәттәшлеге турында мәгълүмат | Актуаль хәлдә саклана | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппаратының оештыру бүлеге башлыгы урынбасары | Мәгълүмат әзерләнгәннән соң 3 эш көне эчендә |
| 15. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы төбәкара шартнамәләрен һәм төбәкара хезмәттәшлек программаларын тормышка | Актуаль хәлдә саклана | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге башлыгы (килешенү буенча) | Мәгълүмат әзерләнгәннән соң 3 эш көне эчендә |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | ашыруда катнашуы турында мәгълүмат | | | |
| 16. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары җитәкчеләренең һәм рәсми делегацияләренең рәсми визитлары һәм эш сәфәрләре турында, шулай ук Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан оештырыла торган рәсми чаралар (утырышлар, очрашулар, брифинглар, семинарлар, "түгәрәк өстәлләр" һәм башка чаралар) турында мәгълүмат, аерым алганда, булачак рәсми визитлар һәм эш сәфәрләре, рәсми чаралар һәм аларның нәтиҗәләре турында да | Рәсми визит анонслары (эш сәфәре, рәсми чара) - әлеге чаралар башланганчы бер эш көне дәвамында. Рәсми визит нәтиҗәләре (эш сәфәре, рәсми чара) - күрсәтелгән чаралар тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппараты җитәкчесе | Рәсми визит анонслары (эш сәфәре, рәсми чара) – әлеге чаралар башланганчы ике эш көненнән дә соңга калмыйча. Рәсми визит нәтиҗәләре (эш сәфәре, рәсми чара) - әлеге чаралар тәмамланган көн дәвамында |
| 17. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары җитәкчеләре һәм җитәкчеләре урынбасарларының рәсми чыгышлары һәм белдерүләре текстлары | Чыгыштан соң бер эш көне эчендә | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппараты җитәкчесе | Чыгыштан соң бер эш көне эчендә |
| 18. | Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау торышы һәм аларның иминлеген тәэмин итү буенча кабул ителгән чаралар, фаразланган һәм барлыкка килгән гадәттән тыш хәлләр, алардан халыкны саклау алымнары һәм ысуллары турында мәгълүмат | Актуаль хәлдә саклана | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге башлыгы (килешенү буенча) | Мәгълүмат әзерләнгәннән соң 3 эш көне эчендә |
| 19. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан аларның вәкаләтләре чикләрендә үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре, шулай ук Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә | Тикшерү актларына кул куелганнан соң 5 эш көненнән дә соңга калмыйча | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы рәисе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Контроль-хисап палатасы рәисе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе | Тикшерү актларына кул куелганнан соң 3 эш көненнән дә соңга калмыйча |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | органнарында үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре турында мәгълүмат | | муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппараты җитәкчесе | |
| 20. | Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу турында мәгълүмат | Актуаль хәлдә саклана | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының "Сатып алулар һәм муниципаль контроль идарәсе" муниципаль казна учреждениесе директоры (килешенү буенча) | Мәгълүмат әзерләнгәннән соң 3 эш көне эчендә |
| **IV. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында статистик мәгълүмат** | | | | |
| 21. | Икътисади, социаль һәм башка тормыш эшчәнлеге өлкәләренең торышын һәм үсеш динамикасын характерлаучы статистика мәгълүматлары һәм күрсәткечләре, аларны җайга салу Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә кертелгән | Квартал саен | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге башлыгы (килешенү буенча) | Квартал саен |
| 22. | Бүлеп бирелә торган бюджет акчаларын Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнары һәм аларның ведомство карамагындагы оешмалары тарафыннан куллану турында мәгълүмат | Квартал саен | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе | Квартал саен |
| 23. | Муниципаль ихтыяҗлар өчен сатып алулар барышы турында статистик мәгълүмат (торгларда катнашучыларның уртача саны, | Актуаль хәлдә саклана | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының "Сатып алулар һәм муниципаль | Мәгълүмат әзерләнгәннән соң 3 эш көне эчендә |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | экономия (янга калдыру) проценты | | контроль идарәсе" муниципаль казна учреждениесе директоры (килешенү буенча) | |
| **V. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан оештырылган координацион (яраштыру) һәм киңәшмә органнары турында мәгълүмат** | | | | |
| 24. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан оештырылган координацион һәм киңәшмә органнары исемлеге | Органнар барлыкка килгәннән соң 5 эш көне эчендә | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлеге башлыгы (килешенү буенча) | Органнар барлыкка килгәннән яки аңа үзгәрешләр кертелгәннән соң 3 эш көне эчендә |
| 25. | Координацион һәм киңәшмә органнары эшчәнлеген булдыруны һәм хокукый нигезен көйләүче норматив хокукый һәм башка актлар | Норматив хокукый актларга кул куелганнан соң 5 эш көне эчендә | Координация һәм киңәшмә органнары сәркатипләре | Норматив хокукый актларга кул куелганнан соң 3 эш көне эчендә |
| 26. | Координацион һәм киңәшмә органнары составы турында мәгълүматлар (координация һәм киңәшмә органнары җитәкчеләренең һәм әгъзаларының фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре, вазыйфалары), шулай ук урнашу урыны адресы, телефон номерлары (факс), электрон почта адресы | Норматив хокукый актларга кул куелганнан соң 5 эш көне эчендә | Координация һәм киңәшмә органнары сәркатипләре | Норматив хокукый актларга кул куелганнан соң 3 эш көне эчендә |
| 27. | Координацион һәм киңәшмә органнары утырышлары турында мәгълүмат, аерым алганда, утырышлар анонслары, координацион һәм киңәшмә органнары утырышлары беркетмәләре | Утырыш анонслары утырышка кадәр 3 эш көненнән дә соңга калмыйча. Имзаланганнан соң 5 эш көне эчендә утырышлар беркетмәләре | Координация һәм киңәшмә органнары сәркатипләре | Утырышлар анонслары утырышка кадәр 5 эш көненнән дә соңга калмыйча. Беркетмә имзаланганнан соң 3 эш көне эчендә утырышлар беркетмәләре |
| **VI. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарын** | | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **кадрлар белән тәэмин итү турында мәгълүмат** | | | | |
| 28. | Гражданнарның муниципаль хезмәткә керү тәртибе | Актуаль хәлдә саклана | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппаратының кадрлар секторы мөдире | Мәгълүмат әзерләнгәннән соң 3 эш көне эчендә |
| 29. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарындагы муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфалары турында мәгълүмат | Вакантлы вазыйфа игълан ителгәннән соң 3 эш көне эчендә | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппаратының кадрлар секторы мөдире | Вакантлы вазыйфа игълан ителгәннән соң 2 эш көне эчендә |
| 30. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарында Татарстан Республикасы муниципаль хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә кандидатларга квалификация таләпләре | Таләпләр расланганнан соң 5 эш көне эчендә | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппаратының кадрлар секторы мөдире | Таләпләр расланганнан соң 3 эш көне эчендә |
| 31. | Муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурс шартлары һәм нәтиҗәләре | Конкурс шартлары конкурс уздырылганчы 5 эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла. Нәтиҗәләр - конкурс узганнан соң 3 эш көне эчендә | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппаратының кадрлар секторы мөдире | Конкурс шартлары конкурс уздырылганчы 7 эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштыру өчен бирелә. Нәтиҗәләр - конкурс үткәрелгәннән соң 2 эш көне эчендә |
| 32. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарында вакантлы вазыйфаларны биләү мәсьәләсе буенча мәгълүмат алырга мөмкин булган телефон номерлары, электрон почта адресы | Актуаль хәлдә саклана | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппаратының кадрлар секторы мөдире | Мәгълүмат әзерләнгәннән соң 3 эш көне эчендә |
| 33. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең | Комиссия составы расланганнан соң 5 эш көне эчендә | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппаратының кадрлар секторы мөдире | Комиссия составы расланганнан соң 3 эш көне эчендә |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурсларны оештыру һәм үткәрү буенча комиссияләр составы | | | |
| 34. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарына муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурс нәтиҗәләренә шикаять бирү тәртибе | Тәртип расланганнан соң 5 эш көне эчендә | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппаратының юридик бүлеге башлыгы | Тәртип расланганнан соң 3 эш көне эчендә |
| 35. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарына буйсынучы мәгариф оешмалары исемлеге (булган очракта), аларның почта адресларын, рәсми сайт адресларын, шулай ук телефон номерларын күрсәтеп, алар буенча әлеге белем бирү оешмалары турында белешмә характерындагы мәгълүматны алырга мөмкин | Актуаль хәлдә саклана | «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе башлыгы (килешенү буенча) | Исемлек расланганнан яки аңа үзгәрешләр кертелгәннән соң 3 эш көне эчендә |
| 36. | Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын (низагын) җайга салу буенча комиссияләрнең эш тәртибе, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссиягә карау өчен гаризалар бирү тәртибен дә кертеп | Тәртип расланганнан соң 5 эш көне эчендә | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппаратының кадрлар секторы мөдире | Тәртип расланганнан соң 3 эш көне эчендә |
| 37. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнарында һәм аларның ведомство карамагындагы оешмаларында коррупциягә каршы тору буенча күрелә торган чаралар турында мәгълүмат | Актуаль хәлдә саклана | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча ярдәмчесе | Мәгълүмат әзерләнгәннән соң 3 эш көне эчендә |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **VII. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарының гражданнар (физик затлар), оешмалар (юридик затлар), иҗтимагый берләшмәләр, дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары мөрәҗәгатьләре белән эшләве турында мәгълүмат** | | | | |
| 38. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнарында һәм аларның ведомство карамагындагы оешмаларында гражданнар (физик затлар), оешмалар (юридик затлар), иҗтимагый берләшмәләр, дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары мөрәҗәгатьләре белән эшләү мәсьәләләрен көйләүче норматив хокукый һәм башка актлар | Норматив хокукый һәм башка акт расланганнан соң 5 эш көне эчендә | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппараты җитәкчесе | Норматив хокукый һәм башка акт расланганнан соң 3 эш көне эчендә |
| 39. | Гражданнар (физик затлар), оешмалар (Юридик затлар), иҗтимагый берләшмәләр, дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе | Актуаль хәлдә саклана | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппараты җитәкчесе | Тәртип расланганнан яки аңа үзгәрешләр кертелгәннән соң 3 эш көне эчендә |
| 40. | Гражданнарны (физик затларны), шул исәптән оешма (юридик затларны), иҗтимагый берләшмәләр, дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары вәкилләрен кабул итү тәртибе һәм вакыты | Тәртип расланганнан соң 5 эш көне эчендә | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппараты җитәкчесе | Тәртип расланганнан соң 3 эш көне эчендә |
| 41. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органының структур бүлекчәсе яки башка вазыйфаи зат җитәкчесе һәм ведомство карамагындагы оешма җитәкчесенең фамилиясе, исеме һәм атасының исеме, аларның вәкаләтләренә гражданнарны, шул исәптән оешма, иҗтимагый берләшмә, дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары вәкилләрен кабул итүне оештыру, аларның хәбәрләрен карауны тәэмин итү керә, шулай ук белешмә | Билгеләнгәннән соң 5 эш көне дәвамында | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппараты җитәкчесе | Билгеләнгәннән соң 3 эш көне дәвамында |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | характерындагы мәгълүматны алырга мөмкин булган телефон номеры, электрон почта адресы | | | |
| 42. | Гражданнарның, шул исәптән оешмаларның, иҗтимагый берләшмәләрнең, дәүләт органнарының һәм җирле үзидарә органнарының мөрәҗәгатьләренә күзәтүләр, шулай ук әлеге мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре һәм кабул ителгән чаралар турында гомумиләштерелгән мәгълүмат | Квартал саен | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппаратының оештыру бүлеге башлыгы урынбасары һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлеге башлыгы | Квартал саен |
| **VIII. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнары карамагындагы муниципаль мәгълүмат системалары турында мәгълүматлар** | | | | |
| 43. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары карамагындагы муниципаль мәгълүмат системалары, мәгълүмат банклары, реестрлар, регистрлар исемлеге | Актуаль хәлдә саклана | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының гомуми бүлеге башлыгының мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүмати куркынычсызлык буенча урынбасары (килешенү буенча) | Исемлек расланганнан яки аңа үзгәрешләр кертелгәннән соң 3 эш көне эчендә |
| 44. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнары һәм аларга буйсынучы оешмалар карамагындагы муниципаль мәгълүмат системаларына кызыксынучы затларның алардан файдалану һәм керү шартларын һәм тәртибен тасвирлау, шул исәптән мәгълүмат системаларына керү яки мәгълүмат системаларыннан мәгълүмат алу түләүлелеге турында мәгълүмат | Керү шартлары һәм тәртибе расланганнан соң 5 эш көне эчендә | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының гомуми бүлеге башлыгының мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүмати куркынычсызлык буенча урынбасары (килешенү буенча) | Керү шартлары һәм тәртибе расланганнан соң 3 эш көне эчендә |
| 45. | Муниципаль мәгълүмат системаларын булдыру, алып бару тәртибен көйләүче норматив хокукый һәм башка актлар, шулай | Норматив хокукый һәм башка актларга кул куелганнан соң 5 | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының гомуми бүлеге | Норматив хокукый һәм башка актларга кул куелганнан соң 3 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | ук кызыксынган затларның Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм аларга буйсынучы оешмалар карамагындагы муниципаль мәгълүмат системаларындагы мәгълүматка керү тәртибе | эш көне эчендә | башлыгының мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүмати куркынычсызлык буенча урынбасары (килешенү буенча) | эш көне эчендә |
| 46. | Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә Интернет челтәрендә урнаштырылырга тиешле Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында башка мәгълүмат | Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән срокларда | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының гомуми бүлеге башлыгының мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүмати куркынычсызлык буенча урынбасары (килешенү буенча) | Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән срокларда |

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Башлыгының
2023 елның ___13
октябре
219 пг номерлы карары
белән расланды

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтыннан файдалануны тәэмин итүнең технологик, программа һәм лингвистик чараларына таләпләр**

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтыннан файдалануны тәэмин итүнең технологик һәм программа чаралары (алга таба – сайт) кулланучыларга сайтта урнаштырылган мәгълүмат белән танышу өчен гомуми кулланышта булган программа тәэминаты нигезендә керүне тәэмин итәргә тиеш.

2. Сайтны карау өчен компьютерда бу максат өчен махсус төзелгән технологик һәм программа чараларын урнаштыру каралмаска тиеш.

3. Кулланучыга сайт структурасы турында күзаллаулы мәгълүмат бирелергә тиеш.

4. Сайтны алып баруның технологик һәм программа чаралары түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

а) технологик чаралар һәм сайтны алып бару программалары ярдәмендә башкарылган операцияләрне исәпкә алуның электрон журналларын алып бару;

б) көн саен мәгълүматны резерв йөртүчегә күчереп алу, аны күрсәтелгән йөртүчедән торгызу мөмкинлеген тәэмин итү;

в) мәгълүматны юк итүдән, үзгәртүдән һәм аңа керүне тыюдан, шулай ук мондый мәгълүматка карата башка законсыз гамәлләрдән саклау;

г) сайтта урнаштырылган мәгълүматны беренчел урнаштырылганнан соң 5 ел дәвамында саклау.

5. Сайттагы мәгълүмат рус һәм татар телләрендә урнаштырылырга тиеш.

Чит ил юридик затларының исемнәрен (аталышларын), физик затларның фамилияләрен һәм исемнәрен латин алфавиты хәрефләрен кулланып күрсәтергә рөхсәт ителә.